| | |
|---|---|
| **Республика Татарстан**<br>**Совет Чукмарлинского**<br>**сельского поселения**<br>**Сармановского**<br>**муниципального района** | **Татарстан Республикасы**<br>**Сарман муниципаль**<br>**районы Чукмарлы авыл**<br>**җирлеге советы** |

РЕШЕНИЕ

КАРАР

2019 ел 14 ноябрь — Чукмарлы авылы — № 24

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Чукмарлы авыл җирлеге составына керүче Чукмарлы авылында 2020 елда гражданнарның үзара салымын кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Чукмарлы авыл җирлеге советы карар итте:

1. 2020 елда Чукмарлы авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 1 нче төркем инвалидлардан, ялгыз өлкән гражданнардан, вакытлы хәрби хезмәт үтүче гражданнардан, көндезге уку йортлары студентларыннан тыш, 200 сум күләмендә үзара салым кертергә.

2. Алынган акчаларны түбәндәге җирле мәсьәләләрне хәл итәргә тотарга:

- Чукмарлы авылы зиратын коймасын олешчэ тозеклэндеру башкарылган эшләргә түләү;
- Чукмарлы авылындагы юлларны кыш көне кардан чистарту;
- Чукмарлы авылында мәдәни чаралар уздыру өчен бүләкләр алу (Сабантуй, өлкәннәр көне, 9 Май)

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә һәм Чукмарлы авылы, Совет урамы, 41 йорт адресы буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Совет Рәисе
Чукмарлы авыл җирлеге башлыгы — И.Х.Хадиуллин